| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Югары<br>Чыршылы авыл җирлеге<br>башкарма комитеты |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

31.01.2022 г.

№ 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитетының 29.01.2021 елның 1 нче санлы “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль район
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.Н.Камалетдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1061687003113 Исполнительный комитет Верхне-Чершилинского сельского поселения Югары Чыршылы авыл җирлеге Башкарма комитеты ИНН 1636005623 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3816,88 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1330,30 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1817,50 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2022 елның 31 гыйнварындагы
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 670,54 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3146,34 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1330,30 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1817,50 |
| Барлыгы | 6964,68 |